| ГЛАВА<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2022 ел Борындык авылы №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Борындык авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2022 елның 22 ноябренә 10 сәг 00 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 1 нче А номерлы йорт адресы буенча урнашкан янгын сүндерү депосы янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2022 елның 22 ноябренә 14 сәг 00 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 24 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2022 елның 23 ноябренә 10 сәг 00 минутка Борындык авылы, Октябрь урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** билгеләргә.
4. 2022 елның 24 ноябренә 14 сәг 00 минутка Борындык авылы, К.Маркс урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан Борындык авыл җирлеге советы зданиесе янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык торак пунктында ***үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын*** билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Борындык авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара

салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

авыл җирлеге территориясен төзеклəндерү:

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- җәяүлеләр күперен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен карап тору һәм моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алу;
- су башнясын карап тору;

авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:

- янгын сүндерү машинасын, янгын сүндерү депосы җиһазларын һәм бүлмәләрен карап тору.
- Борындык авылында янгын куркынычсызлыгы чараларын булдыру өчен сулыкларны су белән тәэмин итү буенча эшләрне гамәлгә ашыру;

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге башкарма комитетына, җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен, акча тотарга рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ»

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге Башлыгы А. Р. Гайнетдинов